**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 23 август № 615

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татар халкының милли үзенчәлеген саклау (2014 - 2016 еллар)» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 21 октябрь, 785 нче карары белән расланган «Татар халкының милли үзенчәлеген саклау (2014 - 2016 еллар)» Татарстан Республикасы дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татар халкының милли үзенчәлеген саклау (2014 - 2016 еллар)» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 21 октябрь, 785 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 6 июнь, 381 нче карары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) расланган «Татар халкының милли үзенчәлеген саклау (2014 - 2016 еллар)» Татарстан Республикасы дәүләт программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге дәүләт программасының I бүлегендәге унсигезенче абзацта «тормышка ашырыла» сүзләрен «тормышка ашырылды» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге дәүләт программасына кушымтада:

1.3 пунктның 2 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ТР МһФМ, «ТР ФА Ш.Мәрҗәни исемендәге тарих институты» ДБУ, БТКБК (килешү буенча), ТФММА (килешү буенча), К(Иб)ФУ (килешү буенча)»;

1.5 пунктның 2 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ТР МһФМ, «ТР ФА Ш.Мәрҗәни исемендәге тарих институты» ДБУ, БТКБК (килешү буенча), К(Иб)ФУ (килешү буенча), РТИ (килешү буенча)»;

1.7 пунктның 2 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ТР МҺФМ, «ТР ФА Ш.Мәрҗәни исемендәге тарих институты» ДБУ, БТКБК (килешү буенча), ТММЖ (килешү буенча)»;

1.9 пунктның 2 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ТР МҺФМ, «ТР ФА Ш.Мәрҗәни исемендәге тарих институты» ДБУ, ТР МК каршындагы ДАУ (килешү буенча), БТКБК (килешү буенча)»;

1.10 пунктның 2 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ТР МҺФМ, «ТР ФА Ш.Мәрҗәни исемендәге тарих институты» ДБУ, РТИ (килешү буенча), БТКБК (килешү буенча)»;

1.12 пунктның 1 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.12. Татарстан Республикасыннан читтә урта гасыр төрки-татар шәһәрләрен тарихи-археологик тикшеренүләр үткәрү: Үкәк (Саратов өлкәсе), Искәр (Төмән өлкәсе), Красноярск шәһәрчеге (Әстерхан өлкәсе), Кызыл сөендек шәһәрчеге (Ульяновск өлкәсе), Касыйм (Рязань өлкәсе), Кормыш (Нижегород өлкәсе), Маҗар (Ставрополь өлкәсе), шулай ук Кырымның (Кырым Республикасы) урта гасыр төрки-татар халкының тарихи-археологик мирасын өйрәнү»;

4.6 пунктның 1 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.6. Бөтенроссия авыл Сабантуе кысаларында Бөтендөнья татар конгрессы кубогына Бөтенроссия ат чабышлары үткәрү»;

4.7 пунктта:

3 графада «2014 – 2016 еллар» сүзләрен «2015 ел» сүзләренә алмаштырырга;

6 һәм 8 графаларда «189» һәм «191» саннарын «-» билгесенә алмаштырырга;

файдаланылган кыскартулар исемлегенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«ТР ФА Ш.Мәрҗәни исемендәге тарих институты» ДБУ - «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗәни исемендәге тарих институты» дәүләт бюджет учреждениесе.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков